ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.02.2020 ел Баулы шәһәре №22

Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри несхәсе турында

«Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында»гы 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы (2016 елның 3 июлендәге ред.), «Китапханә эше турында»гы 1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ (2009 елның 1 маендагы ред.) федераль законнар нигезендә, китапханә-мәгълүмат фондын туплау, муниципаль берәмлек документларының мәҗбүри несхәсенең сакланышын, халыкның алардан файдалана алуын тәэмин итү максатында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри несхәсе турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Үзәк китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри несхәсе составына керүче документларны алу, саклау һәм халыкның алардан файдалана алуын тәэмин итү хокукын бирергә.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ «Экстремистик материалларның федераль исемлегенә» кертелгән документлар белән эшләү буенча инструкция эшләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 4 февралендәге
22 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри нөсхәсе турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри несхәсе турында әлеге нигезләмә (алга таба - нигезләмә) «Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында»гы 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы, «Китапханә эше турында»гы 1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ (2009 елның 1 маендагы ред.) федераль законнар нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Үзәк китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенә (алга таба – «ҮКС» МБУ) түләүсез тапшырылырга тиешле документлар төрләрен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри нөсхәсен кабул итүче булып Баулы муниципаль районы территориясендә мәҗбүри нөсхәне алу, саклау һәм халыкның алардан файдалана алуын тәэмин итү хокукына ия «ҮКС» МБУ тора.

1.3. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри нөсхәсе булып Баулы муниципаль районы территориясендә һәм (яки) аның территориясеннән читтә Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге карамагындагы оешмалар заказы буенча әзерләнгән нөсхәләр, «ҮКС» муниципаль бюджет учреждениесенә түләүсез тапшырылырга тиешле тираж документларының төрле төрләре тора.

1.4. Предприятиеләргә, учреждениеләргә, барлык милек формасындагы оешмаларга Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри нөсхәсе белән эшләүне оештырганда әлеге Нигезләмәгә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

1.5. Әлеге Нигезләмә шәхси һәм гаилә серен үз эченә алган документларга; дәүләт, хезмәт һәм (яки) коммерция сере булган документларга; бер генә үтәлештә тезелгән документларга; архив документларына (материалларына) («Документларның мәҗбүри несхәсе турында»гы 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль законның 12, 18, 19 статьялары нигезендә архив учреждениеләренә саклауга тапшырыла торган документлардан тыш); мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып гына таратыла торган электрон документларга; идарә итү һәм техник документларга (эксплуатацияләү буенча формулярлар, инструкцияләр, бланклы продукция, хисап һәм хисап документлары формалары альбомнары) кагылмый.

## 2. Документларның мәҗбүри нөсхәсе составы һәм төп төшенчәләр

Документларның мәҗбүри нөсхәсенең составы һәм төп төшенчәләр «Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» гы 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән.

## 3. Документларның мәҗбүри несхәсе составына керүче документлар төрләре

Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының мәҗбүри нөсхәсе составына түбәндәге документлар керә:

- редакция-нәшрият эшкәртүен узган, полиграфик яктан мөстәкыйль рәсмиләштерелгән, нәшрият итү турында мәгълүматы булган басмалар (текстлар, ноталар, картография, рәсемнәр);
- басма басманың электрон рәвештәге несхәсе - оригинал-макетның электрон күчермәсе (бастырылган документтагы (басмадагы) мәгълүматны, шул исәптән текстны, иллюстрацияләр һәм бизәлешнең барлык элементларын яңадан чыгаручы);
- сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен басмалар - Брайль системасы буенча рельеф-нокталы шрифт белән җитештерелә торган басмалар, рельеф-графиклы басмалар, “сейләүче китаплар", начар күрүчеләр өчен зур шрифтлы басмалары, сукырлар өчен электрон басмалар (Брайль дисплее һәм сөйләм синтезаторы ярдәмендә начар күрүчеләр ечен җайлаштырылган басмалар);
- мәҗбүри, тәкъдим итү яки мәгълүмати характердагы закон чыгару, башкарма хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән рәсми документлар;
- теләсә нинди төрдә дә төшерелгән аудиовизуаль продукция - кино, видео-, фоно-, фотопродукция;
- электрон басмалар - мәгълүмат электрон-цифрлы формада тәкъдим ителгән һәм редакция-нәшрият эшкәртүен узган, нәшрият итү турында мәгълүматы булган, тиражлана һәм мәгълүмат йөртүче җайланмаларда таратыла торган документлар;
- фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрне (диссертацияләр) нәтиҗәләрен, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм

технологик эшләр турында хисапларны, саклана торган фәнни эшләрне, алгоритмнар һәм программаларны үз эченә алган) басылып чыкмаган документлар;

- катнаш документлар - төрле чыганакларда (басма, аудиовизуаль, электрон) башкарылган документлар җыелмасы;

- теләсә нинди төрдә төшерелгән аудиовизуаль продукция – кино-, видео-, фоно-, фотопродукция һәм аларның комбинацияләре.

## 4. Документларның мәҗбүри нөсхәсе системасы формалаштыру максатлары һәм бурычлары

4.1. Әлеге Нигезләмәнең максатлары булып торалар:

- Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль китапханә фондының бер елеше буларак тулы китапханә-мәгълүмат фондын туплау һәм бу хакта муниципаль берәмлек китапханәсеннән файдаланучыларга хәбәр итү;

- муниципаль китапханә фондын кулланучыларга мәгълүмати-библиография һәм китапханә хезмәте күрсәтүдә куллану.

4.2. Әлеге Нигезләмәнең бурычлары булып тора:

- фондны даими саклауны оештыру;

- китапханәләрдән файдаланучыларга алынган мәҗбүри документлар турында мәгълүмат бирү;

- экстремистлык (террорчылык) эшчәнлеген профилактикалау;

- җирле үзидарәгә мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

- халык мәҗбүри экземплярлар турында мәгълүматтан файдалана алсын өчен шартлар тудыру;

- Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәҗбүри алына торган документларның төрләре нигезендә үзәкләштерелгән каталогизацияне алып бару.

## 5. Документларның мәҗбүри нөсхәсен җитештерүченең һәм кабул итүченең хокуклары һәм бурычлары

5.1. Документлар җитештерүчеләр мәҗбүри документлар нөсхәләрен полиграфик оешмалар аша Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең документлар алу хокукына ия булган китапханәләренә тиражның беренче партиясе дөнья күргән көнне түләүсез нигездә тапшыралар. Документларның мәҗбүри экземплярына керүче барлык документларның ике

мәҗбүри нөсхәсен, балалар өчен билгеләнгән басмаларның ике мәҗбүри несхәсен, шулай ук үсеп килүче буынны тәрбияләү буенча белешмә һәм методик басмаларны түбәндәге санда:

- кәгазь басмалар - тиражның беренче партиясе чыккан кенне ике нөсхәдә;

- электрон басмалар - бер нөсхә, тиражның беренче партиясе дөньяга чыккан көннән алып утыз көн эчендә;

- муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән рәсми документлар - бер нөсхә, кул куелган кеннән җиде көн эчендә.

Документлар җитештерүчеләр мәҗбүри нөсхәдә документлар алучыга сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен басмаларның бер мәҗбүри нөсхәсен тапшыралар.

5.2. Документлар җитештерүчеләр мәҗбүри нөсхә составына керүче документларның үзкыйммәтенә мәҗбүри экземплярларны әзерләү, бастырып чыгару һәм җибәрү (тапшыру, китерү) чыгымнарын кертә.

5.3. Документларның дефектлы мәҗбүри нөсхәсен документны җитештерүче документларның мәҗбүри нөсхәсен алучы соравы буенча бер ай эчендә алмаштырыла.

5.4. Катнаш документлардан торган документларның мәҗбүри нөсхәсе мәҗбүри нөсхә алучыларга бердәм комплект белән җибәрелергә тиеш.

5.5. Мәҗбүри документлар нөсхәсен тулы һәм оператив китерү документларны җитештерүчеләргә түбәндәге хокукларны гарантияли:

- алар җитештергән документларны даими саклау;

- Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең автоматлаштырылган мәгълүматлар базасына библиографик мәгълүматны кертү;

- аларның продукцияләренә кагылышлы фактографик һәм статистатистик мәгълүматларны түләүсез бирү;

- документларның мәҗбүри нөсхәсен алучылар тарафыннан документлар җитештерүчеләрнең хокукларының Россия Федерациясенең интеллектуаль милек турындагы законнарына ярашлы рәвештә үтәү;

- мәҗбүри нөсхә китерүне язмача раслау.

## 6. Баулы муниципаль районында мәҗбүри документлар нөсхәсен алучылар

Баулы муниципаль районында мәҗбүри документлар нөсхәсен алучы булып «ҮКС»" МБУ тора, ул түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- тиешле төрдәге документларның мәҗбүри нөсхәсен алып килүне тикшерү;

- документларны библиографик теркәү, аларның статистик һәм башка норматив исәпкә алу;

- кулланучыларга документларның мәҗбүри нөсхәсе турында мәгълүмат бирү;

- муниципаль берәмлек документларының тулы комплектын җыю һәм аларны даими саклау;

- документларның мәҗбүри нөсхәсен саклауны һәм файдалануны тәэмин итү;

- документларның сакланышы һәм алардан файдалану;

- гражданнарга һәм оешмаларга китапханә-мәгълүмати хезмәт күрсәтү максатларында, гражданлык законнары нигезендә мәҗбүри документларның күчермәләрен алу һәм репродукцияләү;

- дәүләт хакимияте органнары, суд һәм хокук саклау органнары запрослары буенча теркәлгән документларның күчермәләрен һәм документларны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр бирү;

- муниципаль берәмлекнең мәҗбүри нөсхәсе документларының барлык төрләре буенча мәгълүматларның җыелма библиографик базасын формалаштыру;

- документлар алучы мәҗбүри экземплярларны, җитештерүчеләр китермәгән очракта, сатып алырга хокуклы.

## 7. Документларның мәҗбүри нөсхәсен китерүне контрольдә тоту

7.1. Документларның мәҗбүри несхәсен алучыга җиткерүне контрольдә тоту документларның мәҗбүри нөсхәсен теркәү һәм исәпкә алуны гамәлгә ашыручы «ҮКС» МБУгә йөкләнә.

7.2. Документларның мәҗбүри нөсхәсен алучы, документлар билгеләнгән срокларда килмәсә яки тулы булмаган күләмдә килсә, 3 көн эчендә җитештерүчегә документларның мәҗбүри несхәсен тапшыру яисә тулы күләмдә тапшыру турында таләпне җибәрә. Документларның мәҗбүри нөсхәсен җитештерүче таләп алынганнан соң 10 көн эчендә таләпне карый һәм мәҗбүри документлар нөсхәсен алучыга җавап җибәрә. Таләпне канәгатьләндерүдән баш тарткан яки аңа җавап бирмәгән очракта, әлеге пункт белән билгеләнгән срокта, документлар нөсхәсен алучы документларның мәҗбүри нөсхәсен бирүне контрольдә тотучы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә язмача хәбәрнамә җибәрә.

7.3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә мәҗбүри документлар нөсхәсен алучы тарафыннан җибәрелә торган язма хәбәрнамәдә мәҗбүри нөсхә алучыга үз вакытында яки тулысынча тапшырылмаган документларның исеме һәм саны, исеме,

кәгазь басманың беренче партиясе яки электрон басма тиражының дөньяга чыгу көне турында белешмә, рәсми документка кул куелган көн, мәҗбүри документлар басылу турында мәгълүмат, әлеге нигезләмәдә каралган документларның мәҗбүри несхәсен китерү тәртибен бозуга юл куйган җитештерүченең исеме һәм адресы.

7.4. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге документларының җитмәве, вакытында килмәве яки тулы булмаган несхәсе килүе турында белешмәләр «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә тапшырыла.

7.5. Документларның мәҗбүри нөсхәсен бирүне контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ башкара.

7.6. Документларның мәҗбүри нөсхәсен тапшырмаган, үз вакытында тапшырмаган һәм (яки) тулы булмаган килеш тапшырган өчен документлар җитештерүчеләр административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.